КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 711

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән расланган Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 138 нче; 2018 ел, 2 апрель, 200 нче; 2018 ел, 5 июнь, 425 нче; 2018 ел, 4 июль, 550 нче; 2018 ел, 8 декабрь, 1090 нчы; 2019 ел, 25 гыйнвар, 41 нче; 2019 ел, 28 февраль, 148 нче; 2019 ел, 26 апрель, 347 нче; 2019 ел, 29 апрель, 350 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә, 10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«2019 елның 1 июленнән субсидияләр күләмен исәпләү Россия Федерациясе Үзәк Банкының рефинанслау ставкасы (хисап ставкасы) яисә 2019 елның 1 июленә гамәлдә булган Төп ставка буенча гамәлгә ашырыла.

Әгәр Россия Федерациясе Үзәк Банкының рефинанслау (хисап ставкасы) ставкасының яисә 2019 елның 1 июленә төп ставканың әһәмияте Россия

Федерациясе Үзәк Банкының рефинанслау ставкасының (хисап ставкасы) күләменнән яки кредит шартнамәсен (займ килешүе) төзү датасына төп ставкадан артса, ә өстәмә килешү, Банк хәбәрнамәсе яисә Кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) башка документ булганда, кредиттан (займнан) файдаланган өчен түләү күләмен үзгәртүгә бәйле рәвештә Кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә), – Кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) тиешле документ төзү датасына субсидияләр исәпләү Россия Федерациясе Үзәк Банкының рефинанслау (хисап ставкасы) ставкасы яки кредит шартнамәсен (займ шартнамәсе) төзү датасына гамәлдә булган Төп ставка буенча, ә кредиттан (займнан) файдаланган өчен түләү күләмен үзгәртүгә бәйле өстәмә килешү, Банк хәбәрнамәсе яисә Кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) башка документ булган очракта – Кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) тиешле документ төзү датасына гамәлгә ашырыла.».

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин